Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советы

Питрәч авыл җирлеге Башлыгы
# КАРАРЫ

26 октябрь, 2022

№ 8

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Шихазда авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге уставының 24.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 ноябрендәге 146 номерлы (2021 елның 17 декабрендәге 34 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) карары нигезендә карар бирәм:

1. Питрәч авыл җирлегенең Шихазда авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

Гражданнар җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабын 2022 елның 12 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 51 йорт буенча урнашкан авыл клубы бинасы янында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Үзәк урамы буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабын 2022 елның 13 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 51 йорт буенча урнашкан авыл клубы бинасы янында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Тау асты, Шоссе урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2023 елда Питрәч авыл җирлеге, Шихазда авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә

ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- Шихазда авылы зиратына койма тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ